**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2026 елның 15 маендагы 780/ПИК номерлы

# КАРАР

**«Ваклап сату базарларын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 4 сентябрендәге 1543 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. «Ваклап сату базарларын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 4 сентябрендәге 1543 номерлы карарының преамбуласына үзгәрешләр кертергә, андагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында»гы карары белән алыштырырга.

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Т. Ильясовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Т. Гарифуллин